ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘРӘКӘШЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
(IV чакырылыш)

**IV чакырылышның чираттан тыш утырыш**
**КАРАРЫ**

**№ 7** **Кәрәкәшле ав.** **14 март 2025 ел**

Ютазы муниципаль районының
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы,
Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы депутаты,
Ютазы район Советы депутаты
вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 36 статьясындагы 6 өлешенең 2 пункты, 40 статьясындагы 10 өлешенең 2 пункты, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 24, 29 статьялары, 45 статьясындагы 1 өлешенең 2 пункты, 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының « Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 51 статьясындагы 1 өлеше, Дәүләтгәрәев Альфред Габделрәшит улының Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы, Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы гаризасын карап, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы карар кабул итте::

1. Вакытыннан алда туктатырга:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы Дәүләтгәрәев Альфред Габделрәшит улының үз теләге белән отставкага китүенә бәйле рәвештә вәкаләтләре 14.03.2025 ел;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы депутаты Дәүләтгәрәев Альфред Габделрәшит улының, 10 нчы Кәрәкәшле бер мандатлы сайлау округы депутатының үз теләге белән 14.03.2025 елда отставкага китүенә бәйле вәкаләтләре.

2. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы вәкаләтләрен вакытлыча башкаруны азат ителмәгән нигездә Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы урынбасары Мәрданова Зөлфия Әнфәс кызына 15.03.2025 елдан алып Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының яңа сайланган Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы вазыйфасына керешкәнче йөкләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хакимияте һәм җирле

үзидарә органнарының Бердәм «Рәсми Татарстан» порталын урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә: http://jutaza.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының « Кәрәкәшле авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге торак пунктлары территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында: Кәрәкәшле авылы, Мирфатыйх Зәкиев урамы, 19 йорт ( Кәрәкәшле авыл мәдәният йорты); Салкын Чишмә авылы, Фрунзе урамы, 4а йорт (Салкын Чишмә авыл клубы); Урал авылы, Урал урамы, 3а йорт (күпфункцияле үзәк бинасы); Ак Чишмә авылы 24а номерлы йорт янында.

4. Әлеге карар кабул ителгән көннән үз көченә керә.

Кәрәкәшле авыл җирлеге
Башлыгы урынбасары З. Ә. Мәрданова